**СОВЕТ ГОРОДА МАМАДЫШ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**ул. М. Джалиля, 23/33, г. Мамадыш, 422190**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАМАДЫШ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**
**М.Җәлил ур., 23/33, Мамадыш ш., 422190**

**тел.:(85563) 3-15-90, факс 3-24-00 ; e-mail:gorsovet.mamadysh@tatar.ru**

**РЕШЕНИЕ**
**№ 2-23**

**КАРАР**
**«13» август, 2024 ел**

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Башкарма комитетының җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында**

РФдә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Мамадыш шәһәре» Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетына Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәренең түбәндәге вәкаләтләрен тапшыру турындагы мәсьәләне карауны тәкъдим итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булдыру һәм аның эшчәнлеге тәртибен раслау;

җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләү.

2. Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимнәрне кабул иткән очракта, Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре башкарма комитетына:

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

Әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре Советының 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 елларның планлы чорына Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын эшләргә һәм аны бюджет законнары нигезендә карауга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларында, Мамадыш

муниципаль районының рәсми сайтында mamadysh.tatarstan.ru, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Мамадыш шәһәре башлыгы
вазифаларын башкаручы В.А.Захаров